**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 14 март № 140

г. Казань

Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру регламентын раслау турында

Мәгариф өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыручы, үзара хезмәттәшлек итүче Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының нәтиҗәле системасын формалаштыру максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына муниципаль мәгариф бүлекләре (идарәләре) җитәкчеләре һәм муниципаль берәмлекнең гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре вакантлы вазыйфаларын биләү буенча эшне оештырганда Регламент нигезендә эш итәргә тәкъдим итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\140.docx

Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру регламентына кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрына

______________________________________________
(инициаллары, фамилиясе)

____________________________________________
(фамилиясе)

___________________________________________,
(исеме, атасының исеме)

түбәндәге адрес буенча яшәүче_______________________________________
(адресы)

___________________________________________,

тел. ________________________________________
(эш, кәрәзле, E-mail)

Гариза

Миңа Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервына кертү өчен конкурста катнашырга рөхсәт итүегезне сорыйм _____________________________________________________________________
(вазыйфа исеме)
_____________________________________________________________________.

Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру регламенты, шул исәптән вакантлы вазыйфага куелган квалификация таләпләре белән таныштым.

Гаризага теркәлә:

_____________________________________________________________________
(теркәлә торган документлар исемлеге)
_____________________________________________________________________

________________ ________________ ______________________________
(дата) (имза) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру регламенты белән таныштым, шәхси мәгълүматларым белән эш итүгә риза.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 14 март, 140 нчы карары белән расланды

Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру регламенты

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру тәртибен билгели. Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервы законнарда билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына муниципаль мәгариф бүлекләре (идарәләре) җитәкчеләре һәм муниципаль берәмлекнең гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре (алга таба – җитәкчеләр) вакантлы вазыйфаларын биләү өчен кирәкле шәхси, һөнәри һәм эшлекле сыйфатлары булган Россия Федерациясе гражданнарыннан формалаша.

2. Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервының төп бурычлары:

мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрларны сайлап алу, әзерләү һәм дөрес куюның нәтиҗәлелеген тәэмин итү;

Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә профессиональ җитәкчеләр турында мәгълүматлар банкын булдыру.

3. Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру, әзерләү һәм файдалану принциплары:

Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервына кертүнең ирекле булуы;

Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервына кертүгә кандидатларга куелган төп таләпләрнең бердәйлеге;

Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын әзерләү һәм кулланунын нәтиҗәлелеге.

4. Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) формалаштыра.

Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервына кертелгән затлар исемлеген (алга таба – Исемлек) Министрлыкның кадрлар сәясәте бүлеге алып бара.

Исемлек Министрлык раслаган форма буенча алып барыла.

5. Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервы мәгариф бүлекләре (идарәләре) җитәкчеләре вазыйфасына 50 кешедән артмаган һәм муниципаль берәмлекнең гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре вазыйфасына 600 кешедән артмаган санда формалаша һәм Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

## II. Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервына кертү өчен гражданнарны сайлап алу тәртибе

6. Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру буенча чаралар үткәрү өчен Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә.

Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе составына түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры (Комиссия рәисе), Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары (Комиссия рәисе урынбасары), Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры билгеләгән Министрлыкның структур бүлекчәләре җитәкчеләре, белгечләре;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты вәкиле;

Муниципаль берәмлекләр советы рәисе (килешү буенча);

эшчәнлекләре дәүләт хезмәте белән бәйле булган фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белемнең белем бирү оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары вәкиле (вәкилләре) (килешү буенча).

Комиссиянең сан һәм персональ составы, шулай ук эш тәртибе Министрлык боерыклары белән раслана.

7. Югары белеме һәм идарә итү эшчәнлегендә кимендә өч ел стажы булган Россия Федерациясе гражданнары Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервына сайлап алуда катнашуга хокуклы.

8. Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервына кертү өчен гражданнарны сайлап алу процедурасы өч этапта гамәлгә ашырыла.

9. Сайлап алуның беренче этабында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервына кертелү хокукына сайлап алу үткәрү һәм документлар кабул итү турында белдерү бастырыла.

Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервына кертелү өчен сайлап алу үткәрү турында белдерү документлар кабул итү башланганчы 14 календарь көне алдан чыгарыла һәм анда түбәндәге мәгълүматлар була:

Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервына кертүгә кандидатка таләпләр;

әлеге Регламентның 10 пункты нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты;

күрсәтелгән документларны кабул итү башлану һәм тәмамлану вакыты;

сайлап алу чараларын үткәрүнең күздә тотылган көне, урыны һәм тәртибе;

Конкурс турында тулы мәгълүмат чыганагы турында белешмәләр (телефон,

факс, электрон почта, электрон адрес Министрлыкның рәсми сайты).

Шулай ук башка мәгълүмати материаллар да урнаштырыла ала.

10. Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервына кертү өчен түбәндәге документлар тапшырыла:

әлеге Регламентка кушымтага ярашлы форма буенча Комиссия рәисе исеменә шәхси гариза;

паспорт яки аны алыштыручы документ күчермәсе (үзе килгәч, тиешле документ шәхси күрсәтелә);

Министрлык раслаган форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган, фотография теркәлгән анкета;

зарур булган һөнәри белемен һәм квалификациясен, эш стажын раслый торган документлар;

билгеләнгән тәртиптә таныкланган белем турында һәм квалификация хакында, шулай ук граждан теләге буенча – өстәмә һөнәри белем турында, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү хакында  документлар күчермәләре;

билгеләнгән тәртиптә таныкланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе яки гражданның хезмәт эшчәнлеген раслый торган бүтән документлар.

11. Тиешле документларның төп нөсхәләрен билгеләнгән тәртиптә сайлап алу чараларына килгәч, дәгъвачы үзе тапшыра.

Документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру аларны гражданнан кабул итүдән баш тарту өчен нигез була.

12. Дәгъвачылар әлеге Регламентның 10 пункты нигезендә тапшырган документларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия аларга сайлап алуның икенче этабында катнашырга рөхсәт итү яисә әлеге Регламентның 7 пунктындагы таләпләргә туры килмәгән очракта, рөхсәт итүдән баш тарту турында карар кабул итә, бу хакта язмача белдерү мондый карар кабул ителгән көннән соң өч эш көне эчендә  дәгъвачыларның электрон яки почта адресларына юллана.

Беренче сайлап алу этабы нәтиҗәләре буенча Комиссия сайлап алуның икенче этабында катнашуга хокуклы кандидатларның тигез исемлеген төзи.

Сайлап алуның икенче этабында катнашу рөхсәт ителмәгән Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервына дәгъвачы бу карарга Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерә ала.

13. Сайлап алуның икенче этабында Министрлыкның кадрлар сәясәте бүлеге федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килми торган конкурс процедураларыннан файдаланып (резюме һәм биографияне анализлауны, шәхси интервьюны, анкета үткәрүне (шәхси сораунамәләрне дә кертеп), тест үткәрүне, шул исәптән читтән торып (онлайн-режимда), төркемнәрдә дискуссияләр үткәрүне, идарә эшчәнлеген гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча эссе, реферат язуны, һөнәри проблемалы хәлләрне хәл итүне дә кертеп), кирәкле бәяләү чараларын уздыра.

Бәяләү чаралары тест үткәрүне, гамәли биремнәрне, шәхси әңгәмәне үз эченә ала.

14. Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар

резервына кандидатларны бәяләүне үткәрү тәртибе, шул исәптән аны үткәрү алымы Министрлык тарафыннан билгеләнә һәм Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервына кертү өчен сайлап алу үткәрү хакында белдерүдә була.

15. Икенче этапны узу нәтиҗәләре буенча кандидатларның һәрберсенә бәяләмә формалаштырыла, анда белемнәрнең, һөнәри мөһим (идарә) компетенцияләрнең актуаль дәрәҗәсе чагылдырыла.

Әзер бәяләмәләр Комиссия утырышында карап тикшерү өчен тапшырыла.

16. Сайлап алуның өченче этабында Комиссия утырышы үткәрелә, анда Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервына кертү турында мәсьәлә карап тикшерелә.

Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервына кертелү хокукына ия булуны сайлап алу үткәрү өчен Комиссия карап тикшерүенә кандидатларның барлык документлары һәм материаллар тапшырыла.

Сайлап алу беренче һәм икенче сайлап алу этапларын уңышлы узган затлар арасыннан башкарыла.

Сайлап алу процедурасы Комиссия утырышына һәр кандидатның мәҗбүри килүе шартларында үткәрелә.

Комиссия үз гамәлләрендә утырышына бирелгән материаллар, шулай ук кандидатлар белән телдән әңгәмә нәтиҗәләре белән эш итә.

Комиссия тәкъдим ителгән кандидатуралар турында фикер алышканнан соң кандидатны Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервы кертү турында яки тәкъдим ителгән кандидатны кертүдән баш тарту хакында карар кабул итә. Комиссия карары рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм утырышта катнашкан Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

Сайлап алу үткәрү нәтиҗәләре турында мәгълүмат Комиссия тарафыннан Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервына кертү яки кертүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән соң җиде көн эчендә анда катнашкан кандидатларга җиткерелә.

17. Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервы кертелгән затлар исемлеге комиссия тиешле карар кабул иткән көннән соң 10 көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

18. Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервы кандидатлар комиссия карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә дәгъва белдерергә хокуклы.

19. Кабат конкурс процедуралары үтмичә, Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервында булу вакыты өч елдан артык була алмый.

20. Конкурс нигезендә сайлап алуга кертелмәгән дәгъвачыларның һәм конкурс нигезендә сайлап алуда катнашкан кандидатларның документлары конкурс нигезендә сайлап алу тәмамланган көннән соң өч ел эчендә язмача гариза нигезендә аларга кире кайтарылырга мөмкин. Өч ел үткәнче документлар Министрлык архивында саклана, аннан соң юк ителергә тиеш.

## III. Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервыннан файдалану

21. Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервы мәгариф идарәсенең муниципаль органнары җитәкчеләре һәм муниципаль берәмлекнең гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре вакантлы вазыйфаларын биләүгә кандидатлар сайлаганда файдалану өчен тәкъдим ителә.

22. Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервында булган зат түбәндәге очракларда Комиссия карары белән аннан чыгарыла:

әлеге затның Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервыннан чыгу турында язмача гаризасы нигезендә;

медицина бәяләмәсе нигезендә тулысынча эшкә яраксыз дип танылган, законлы көченә кергән суд карары нигезендә хокукка сәләтсез яки өлешчә хокукка сәләтсез дип танылган очракта;

әлеге Регламентның 10 пунктында күрсәтелгән документларда дөрес булмаган мәгълүматлар барлыгы билгеле булган очракта;

аның үлеме очрагында, шулай ук суд тарафыннан үлгән яки хәбәрсез югалган дип танылганда;

аңа карата судның гаепләү хөкеме законлы көченә кергән очракта;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 81 статьясындагы беренче өлешнең 3, 5 – 11 пунктлары, 336 статьясындагы 1 – 2 пунктлар белән каралган нигезләр буенча эштән азат ителүе;

мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервына кертү турында карар кабул ителгән көннән соң өч ел узганнан соң.

______________________________